СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино,423186

Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

КАРАР
Әдәмсә авыл җирлеге Советы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Татарстан Республикасы

2022 елның 16-нче июне № 23-81

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының санын һәм урнашу урыннарын расларга, кушымта нигезендә.
2. Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 21.04.2022 ел. № 21-74 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatrstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак – коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И. Назмутдинова

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге
Советының 2022 елның
16-нче июньның
21-74 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары текстларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен махсус мәгълүмат стендларының саны һәм урнашу урыннары

| Урнашу урыны | Норматив-хокукый акт урнаштыру өчен форма атамасы | Саны, шт. |
|---|---|---|
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Әдәмсә авылы, Үзәк урамы, 10 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Бакташ Авылы Кояшлы урамы, 7 нче йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |